ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«24» декабрь 2020 ел** **№ 1058**

**«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (09.11.2020 редакциясендә), 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законы (2019 елның 29 апреле үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы карары (2020 елның 29 августына үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга.
2. Муниципаль заказчы –Программаның координаторы итеп Арча муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.
3. «Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә Программа чараларын финанслауны тәэмин итәргә.
4. «2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 10 февралендәге 178 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Т.Мөхәммәтшинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
24 декабрь 2020 ел, № 1058
карары белән расланган

**«2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мәдәниятне үстерү»**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Программа Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Арча муниципаль районы Уставы, норматив хокукый актлар, Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” МУ Нигезләмәсе нигезендә эшләнде |
| Муниципаль заказчы - Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | Арча муниципаль районы башкарма комитеты, «Мәдәният идарәсе» МУ, «Арча район мәдәният йорты» МБУ, «Казан арты» Арча тарих-этнография музее» МБУ, «Арча үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ, «Арча балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү МББУ |
| Программаның максатлары | Арча муниципаль районында яшәүчеләрнең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңаларын булдыру, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең район халкы һәм кунаклары өчен җәлеп итүчәнлеген арттыру |

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | 1. Җәмгыять үсешенең иң мөһим ресурсы буларак, алар тарафыннан социаль-мәдәни функцияләр башкару өчен музейларны комплекслы үстерү.<br>2. Гражданнарга мәгълүматтан һәм белемнәрдән ирекле файдалануга конституциячел хокукларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек китапханәләрдә хезмәт күрсәтү системасын үстерү, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли-мәдәни мирасны саклап калу.<br>3. Мәдәни-ял итү эшчәнлеген үстерү, милли- мәдәни традицияләрне, үзешчән сәнгатьне һәм халык иҗатын саклап калу һәм үстерү.<br>4. Регионара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү өчен шартлар тудыру, дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салуны тәэмин итү.<br>5. Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын аларның мәдәни тәңгәлләштерү һәм этномәдәни үсеше факторы буларак популярлаштыру һәм халык иҗатына ярдәм итү, аларны саклап калу, торгызу.<br>6. Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының сакланышын һәм мәдәни мирас объектларыннан файдаланунының нәтиҗәлелелелеген тәэмин итү.<br>7. Бу юнәлештә эшне кызыксындыру максатларында, шул исәптән авыл җирлегендә социаль-мәдәни проектларны гамәлгә ашыру буенча мәдәният өлкәсендә ихтыярый (волонтерлыкка) ярдәм итү өчен шартлар тудыру. |
| Гамәлгә ашыру сроклары | 2021 - 2025 еллар |
| Ярдәмче программалар | 1. «2021 - 2025 елларга музей эшен үстерү, мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, алардан файдалану, популярлаштыру»<br>2. «2021 - 2025 елларга китапханә эшен үстерү»<br>3. «2021 - 2025 елларга мәдәни-ял итү эшчәнлеген үстерү, халык иҗатына ярдәм итү, Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру»<br>4. «2021 - 2025 елларга төбәкара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү» |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2021-2025 елларга Программаны финанслау күләме 571311,25 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 ел - 113 747,5 мең сум<br>2022 ел - 114 720,9 мең сум<br>2023 ел - 114 280,95 мең сум<br>2024 ел - 114 280,95 мең сум<br>2025 ел - 114 280,95 мең сум<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле дәрәҗәдәге бюджетлар булдыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш, шулай ук чараларны финанслауга федераль һәм республика бюджетыннан акчалар бүленергә тиеш. |
| Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары), аның бюджет нәтиҗәлелеге | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>реставрацияләүне таләп итә торган предметлар саныннан төп фондның реставрацияләнгән әйберләре өлешләре,<br>дәүләт исәбенә һәм саклауга куелган музейларның төп фонды предметлары санын ел башына караганда ел ахырына 120 процентка кадәр;<br>янгыннан саклау системалары белән җиһазланган музей мәйданнары өлешен 100 процентка кадәр;<br>төп фонд предметларының гомуми санына карата музей предметларын актив күрсәтүдә җәлеп ителгәннәрнең чагыштырма санын 7,5 процентка кадәр;<br>узган елга карата хисап чорында музейларга йөрү өлешен 105,5 процентка кадәр;<br>узган елга карата хисап чорында гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренең һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларның музейларга йөрү санын 70 процентка кадәр;<br>узган елга карата хисап чорында ачылган үз фондлары күргәзмәләре санын 75 процентка кадәр;<br>электрон каталогка кертелгән музей предметлары санын музей предметларының гомуми санына карата 30 процентка кадәр;<br>хезмәткәрләрнең гомуми санына карата компьютерлаштырылган эш урыннары саны 62 процентка кадәр;<br>район халкының 80 процентына китапханә хезмәте күрсәтү;<br>гомуми кулланылыштагы китапханәләр фондына |

| | |
|---|---|
| | килгән яңа басмалар өлешен 3 процентка кадәр;<br>узган ел белән чагыштырганда цифрлаштырылган басмалар санын ел саен 20 процентка;<br>язылган үзәкләштерелгән басмалар исемнәре санын 10 берәмлеккә кадәр;<br>китапханәләрнең җыелма электрон каталогында библиографик язмалар санын 120 мең берәмлеккә кадәр;<br>компьютер җиһазлары һәм Интернет челтәренә керү мөмкинлеге булган һәркем файдалана алырлык китапханәләр өлешен 100 процентка кадәр;<br>төп чор белән чагыштырганда виртуаль керүдә электрон басмалар санын 70 процентка кадәр;<br>заманча китапханә җиһазлары белән тәэмин ителгән китапханәләр өлешен 70 процентка кадәр;<br>төзелгән модель китапханәләр санын 3 берәмлеккә җиткерү;<br>ел саен уздырылган муниципаль китапханә чаралары санын кимендә 2 берәмлеккә;<br>грантлар буенча ел саен гамәлгә ашырылган китапханә проектлары санын кимендә 2 берәмлеккә;<br>тармак белгечләренең гомуми саныннан ел дәвамында квалификацияне күтәргән белгечләр өлешен 10 процентка кадәр;<br>стационар мәйданчыкларда залларның уртача тулылыгын 90 процентка кадәр;<br>конкурсларда, төрле дәрәҗәдәге фестивальләрдә катнашучылар санын;<br>клуб берләшмәләрендә катнашучылар алган дипломнар санын;<br>программалы массакүләм һәм мәдәни-ял чараларында катнашучыларның өлешен;<br>үзешчән сәнгать берләшмәләре һәм аларда катнашучылар санын;<br>түләүле нигездәге чаралар;<br>район халыкларының этномәдәни үзенчәлеген саклауга юнәлдерелгән мәдәни акцияләр һәм программалар санын;<br>дәүләт органнары, мәдәни-агарту учреждениеләре, милли-мәдәни берләшмәләр, шулай ук аерым гражданнар белән уртак проектлар санын 10 проектка кадәр;<br>Россия төбәкләрендә кимендә татар халкының 2 «Сабантуй» бәйрәмен үткәрү;<br>Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан |

| | |
|---|---|
| | мәдәни мирас объектларының гомуми санынннан канәгатьләнерлек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары өлешен. |
| Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы | Арча муниципаль районы Советы; Арча муниципаль районы башкарма комитеты |

**Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, шул исәптән программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар**

Хәзерге вакытта Арча муниципаль районында 4 төр муниципаль бюджет мәдәният һәм сәнгать учреждениесе эшли. Арча муниципаль районы мәдәният объектларының гомуми челтәре үз эченә 2 филиалы булган 1 музей, 57 һәркем файдалана алырлык китапханә, 75 мәдәни-ял итү тибындагы учреждение, 1 өстәмә белем бирү учреждениесен ала.

Тармакта эшләүчеләрнең гомуми саны 406 кеше, шул исәптән белгечләр - 276. Югары белемле белгечләр - 156 кеше, бу белгечләрнең гомуми санының 57 % ы; урта һөнәри белем белән - 72 кеше (25 %); урта белем белән - 48 кеше (18 %). 2019 ел нәтиҗәләре буенча район мәдәният учреждениеләрендә уртача айлык хезмәт хакы 27706,34 сум тәшкил итә (ХЭСтан башка).

Матди-техник базаны үстерүгә, тармак объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә, мәдәният учреждениеләре җиһазларын комплекслы мәгълүматлаштыруга һәм модернизацияләүгә күп акча тотыла.

2012 елдан башлап республикада «Авыл клублары» республика программасы гамәлгә ашырыла, аның кысаларында Арча муниципаль районында 7 яңа күпфункцияле үзәк (Х.Такташ урамында - 2012 ел, Сикертән, Симетбаш авылларында- 2013 ел, Пөшәнгәр авылы - 2014 ел, Иске Иябаш авылы - 2015 ел, Орнашбаш авылы - 2016 ел, Мөндеш авылы - 2020 ел), авыл мәдәният йортлары һәм клублар (Сарай-Чокырча авылы - 2017 ел, Урта Бирәзә авылы, Түбән Оры - 2018 ел) төзелде.

Республикада шулай ук клуб учреждениеләрен капиталь ремонтлау программасы да гамәлдә. Әлеге программа кысаларында Наласа авыл мәдәният йорты - 2015 елда, Ташкичү авыл мәдәният йорты – 2016 елда, Утар Аты авыл мәдәният йорты - 2017 елда, Иске Чүриле авыл мәдәният йорты - 2019 елда, Сәрдәбаш авыл клубы - 2020 елда төзекләндерелде.

Ел саен, матди-техник базаны ныгыту максатыннан, клуб учреждениеләренә агымдагы ремонт ясала, техник чаралар һәм җиһазлар, тавыш һәм яктылык аппаратурасы, сәхнә киемнәре, музыка кораллары һәм башкалар сатып алына. Мәдәни-ял итү учреждениеләрен (алга таба - КДУ) төзекләндерү, яшелләндерү һәм сәнгати бизәү эшләре алып барыла.

2019 елда клуб учреждениеләре 551562 кеше катнашында 12058 мәдәни-массакүләм чара үткәргән, уртача бер клуб оешмасы елына 154 чара уздыра. Түләүле нигездә 960 мәдәни-массакүләм чара үткәрелгән (дискотекалар, концертлар, спектакльләр), шул исәптән авыл җирлегендә - 815 чара,

тамашачылар саны - 75500 кеше.

Клуб учреждениеләрендә 553 мәдәни-ял итү оешмасы эшли, аларда 6861 кеше катнаша, шул исәптән 222се – 14 яшькә кадәрге балалар өчен, 2664 кеше катнаша. Халыкны җәлеп итү - 13 %.

Иҗади коллективлар: «Арча егетләре», «Ләйсән», «Русская песня», «Арча таңнары», «Яшь йөрәкләр» халык вокаль ансамбльләре, «Шишор» мари фольклор ансамбле, «Арча бизәкләре» халык уен кораллары ансамбле, «Җидегән чишмә», «Сәяра», «Нур», «Сердәш» халык театрлары, «Чордашлар», «Өммегөлсем» халык фольклор коллективлары, Арча балалар сәнгать мәктәбенең балалар иҗат коллективлары эшчәнлеген уңышлы дәвам итәләр.

Ел саен шәһәр һәм район халкы өчен 30га якын зур мәдәни-массакүләм чара, фестиваль һәм конкурслар үткәрелә: «Театр яктылыкка, нурга илтә" театр коллективлары фестивале, "Хәтер чылбыры" фольклор коллективлары фестивале, Бөек Ватан сугышында Җиңүгә багышланган "Буыннар хәтере" фестиваль-конкурсы, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен "Мөмкинлекләре чикле, сәләтләре чиксез" иҗат фестивале, районның эшче яшьләре иҗаты фестивале, иҗади концерт программалары конкурслары, урам бәйрәмнәре, КВН уеннары конкурслары, район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре, авыл хуҗалыгы берләшмәләре һәм авыл җирлекләре көннәре кысаларында ТОСлар һәм ТСЖлар арасында урам ярышлары, «Созвездие-Йолдызлык" эстрада сәнгатенең район яшьләр фестивале, "Арча ягы- данлы Тукай ягы» Республика балалар иҗаты конкурсы, «Сөлге чигәм» район чигү бәйгесе, авыл клублары өчен «Төп йорт килене» район конкурсы, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Габдулла Тукай район конкурсы, шигърият бәйрәме, Җиңү көне, Балаларны яклау көне, Шәһәр көне, Россия көне, Татарстан Республикасы көне, “Арча кичләре» халык бәйрәмнәре, Сабантуй, Нәүрүз, Сөмбелә, Ватанны саклаучылар көне, Халыкара хатын-кызлар көне, Әниләр көне, Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре көне, призывниклар, өлкәннәр, инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәре, Арча һәм Казан шәһәрләрендәге авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә концерт программалары, фотокүргәзмәләр һәм башка чаралар. Балалар өчен профессиональ коллективлар һәм башкаручылар чыгышларын, цирк тамашаларын оештыруга, мәдәният йорты сәхнәсендә балалар һәм өлкәннәр өчен спектакльләр куюга зур игътибар бирелә. 2019 елда шундый 80 нән артык чара оештырылды.

2019 ел нәтиҗәләре буенча музей фондларында предметларның гомуми саны 16480 берәмлек тәшкил итә, шул исәптән төп фонд предметлары - 12784 берәмлек, фәнни-ярдәмче фонд предметлары - 3788 берәмлек. 2019 елда музей фондлары 301 предметка артты (72 берәмлеккә фотографияләр коллекциясе, техника предметлары 15 берәмлеккә, 46 берәмлеккә басма продукция предметлары, 95 берәмлеккә көнкүреш предметлары, 54 берәмлеккә).

Хисап чорында 637 экскурсия үткәрелде, 10776 кеше килде, музейдан тыш экспонатларны 39219 кеше карады. Массакүләм чаралар саны - 114, аларда 8907 кеше катнашты. 49 күргәзмә оештырылды, шул исәптән үз фондларыннан - 6, музей базасында башка фондларны җәлеп итеп бер күргәзмә. Музейдан тыш 4 күргәзмә үткәрелде. Музейлар “Арча хәбәрләре” редакциясе, “Шәһри

Казан”, “Татарстан яшьләре” газеталары (17 басма), “АРЧА” телерадиокомпаниясе (42 радиотапшыру), “Безнең мирас” журналы белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Музейның https://archamuzei.ru/ сайты бар.

2019 елда китапханәләр хезмәтеннән 38506 укучы файдаланды, аларга 881074 китап бирелде. Китапханәгә 467133 кеше килде. Китап фонды 466711 данәдән гыйбарәт, 12397 данә яңа басма килде. Арча үзәк китапханә китапханәчеләре 96689 кеше катнашында 2272 массакүләм чара үткәрде. Укучыларның юбилярлар тормышы һәм иҗаты белән кызыксынуын үстерүгә, иҗади очрашуларга, китап күргәзмәләренең төрле формаларына юнәлтелгән чаралар оештырылды: күргәзмә-хәтер, юбилей күргәзмәләре, истәлекләр, хатирәләр, электрон презентацияләр. Экологик тәрбия, туган якны өйрәнү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, хәрби-патриотик тәрбия, хокукый агарту, өлкәннәргә һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә мәгълүмат алу өчен максималь мөмкинлекләр бирү буенча актив эш алып барылды. Китапханәләрдә укучылар Интернет челтәре хезмәтләреннән түләүсез файдалану мөмкинлегенә ия. Китапханәнең үз сайты бар: https://kitap.tatar.ru/ru/participants/branches/42217083/.

Социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча, мәдәният учреждениеләренең гамәлдәге челтәре халык ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерми. Халык бәяләвендә тиешенчә тәэмин ителмәү беренче чиратта түбәндәге проблемалар белән бәйле:

мәдәният учреждениеләре күрсәтә торган хезмәтләр күләме һәм төрләре гражданнарның ихтыяҗларына, өстенлек бирүләренә, көткәннәргә тулы күләмдә туры килми;

мәдәният учреждениеләренең ял итү һәм иҗади эшчәнлек, белем алу һәм үзлегеңнән белем алу, чаралар уздыру, һәвәскәр берләшмәләр эшчәнлеге өчен заманча югары технологияле җиһазлар белән, шулай ук халыкның төрле категорияләре, шул исәптән аз хәрәкәтләнүчән кешеләр һәм башка тормыш эшчәнлеге өчен мәдәният учреждениеләреннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү чаралары белән җитәрлек дәрәҗәдә җиһазландырылмавы;

фестивальләр һәм сәнгатьнең башка жанрларында программалар (музыкаль, театр), концерт-филармония һәм күргәзмә уздыру өчен югары дәрәҗәдәге эре заманча комплексларга кытлык, концерт һәм башка сәнгать коллективлары өчен база сыйфатында файдаланмау.

Мәдәният өлкәсендәге проблемаларны бетерү механизмы

| Проблеманың эчтәлеге | Бетерү механизмы |
| --- | --- |
| Мәдәни-ял итү тәкъдимнәре гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре диапазонын капламый | Мәдәни-ял итү эшчәнлеге өлкәсенә эшнең яңа формаларын һәм ысулларын кертү |
| Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасының җитәрлек | Матди-техник базаны ныгыту һәм тармакны мәгълүматлаштыру, |

| | |
|---|---|
| дәрәҗәдә үсмәве | җиһазларны модернизацияләү, бюджеттан тыш акчалар, дәүләтнеке булмаган структураларны җәлеп итү, грант эшчәнлеге |
| Инвалидлар, мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен мәдәният учреждениеләренең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы | Мәдәният учреждениеләрен махсус техника белән тәэмин итү, инвалидларга һәм башка аз хәрәкәтләнүче гражданнарга читтән торып хезмәт күрсәтү өчен җайлаштыру |
| Инновацион мәдәни проектларны эшләү һәм гамәлгә кертү зарурлыгы | Инновацион проектларга, иҗади остаханәләргә грант ярдәме |
| Югары иҗади звено квалификацияле кадрлар җитмәү; кинотармакның матди-техник базасын һәм киноҗитештерүгә дәүләт ярдәме җитәрлек дәрәҗәдә булмау | Стационар кинокүрсәтү өчен шартлары булмаган торак пунктларга хезмәт күрсәтү өчен заманча проекция стандартының видеопроекция аппаратурасы булган киновидеохәрәкәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру |

**Программа куйган максатларга ирешүдә каршылыкларның йогынтысын азайту максатыннан, аларны җайга салу һәм идарә итү чаралары**

Программаны гамәлгә ашырганда каршылыкларга анализ ясауны муниципаль заказчы - Программаның координаторы - Арча муниципаль районы башкарма комитеты башкара.

Иң җитди каршылыкка ярдәмче программаларны гамәлгә ашырганда финанс һәм административ каршылыкларны кертергә мөмкин. Финанс каршылыгы Программа буенча кабул ителгән финанс йөкләмәләрен тулы күләмдә үтәмәүдән гыйбарәт. Программа чараларының финанс күрсәткечләренә һәм ирешелгән нәтиҗәләргә бәйле рәвештә күрсәткечләргә ел саен төзәтмәләр кертү финанс каршылыгын бетерүнең махсус ысулы булып тора. Программа чараларын финанслап җиткермәү каршылыгын киметү Арча муниципаль районы бюджетыннан мәдәният, социаль партнерлык өлкәсендә инновацион проектларның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге механизмнарын булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Административ каршылык Программаның нәтиҗәле булмавы белән бәйле, ул ярдәмче программаларның максатларын һәм бурычларын үтәмәүгә китерергә мөмкин. Административ каршылыкны бетерү ысуллары түбәндәгеләр:

Программа чараларының үтәлешен тикшереп тору һәм Программаны гамәлгә ашыруда агымдагы идарә механизмын камилләштерү;

Программаны гамәлгә ашыруның еллык планнарын формалаштыру;

Программаның күрсәткечләрен (индикаторларын) үтәүгә өзлексез мониторинг ясау;

Программаны гамәлгә ашыру барышы турында халыкка мәгълүмат җиткерү һәм бастырылган мәгълүматның ачыклыгы.

Каршылыклар белән идарә итү чараларын кабул итү Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм аның нәтиҗәлелеген һәм күрсәткечләрен бәяләү нигезендә муниципаль заказчы - Программаның координаторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## Программаның төп максатлары, бурычлары, ахыргы нәтиҗәләре һәм аны гамәлгә ашыру сроклары

Программаның максаты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы карары белән расланган «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы (2020 елның 29 августына үзгәрешләр белән) белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт мәдәни сәясәте өстенлекләренә нигезләнгән.

Арча муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү максатыннан, мәдәният һәм сәнгать өлкәсен тотрыклы үстерү өчен тиешле шартлар тудыру белән беррәттән, әлеге Программаның стратегик максаты -Арча муниципаль районында яшәүчеләрнең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм формалаштыру, район халкын һәм кунакларны мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә җәлеп итүчәнлекне арттыру. Бу максатка ирешү өчен системалы характердагы кайбер бурычларны хәл итәргә кирәк, шул исәптән:

җәмгыять үсешенең иң мөһим ресурсы буларак, алар тарафыннан социаль-мәдәни функцияләр башкару өчен музейларны комплекслы үстерү;

гражданнарга аларның мәгълүматтан һәм белемнәрдән ирекле файдалануга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек китапханәләр хезмәте күрсәтү системасын үстерү, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклау;

мәдәни-ял итү эшчәнлеген үстерү, милли -мәдәни традицияләрне, үзешчән сәнгатьне һәм халык иҗатын саклау һәм үстерү;

Арча муниципаль районында кинематография, прокат һәм кинофильмнар күрсәтү өчен тиешле шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклау, торгызу һәм популярлаштыру;

Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының сакланышын һәм алардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү;

төбәкара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү өчен шартлар тудыру;

тармак учреждениеләрен квалификацияле персонал белән тәэмин итү өчен идарә итүнең һәм кадрлар әзерләүнең заманча механизмнарын кертү;

мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге мөнәсәбәтләрдә дәүләт сәясәтен гамәлгә

ашыруны һәм җәйгә салуны, мәдәни мирас объектларын саклауны һәм алардан файдалануны тәэмин итү.

Программа программа чараларын муниципаль дәрәҗәдә гамәлгә ашыруны күздә тота, аларның үзенчәлекле бурычлары тиешле ярдәмче программаларда чагылыш таба.

«2021 - 2025 елларга музей эшен үстерү, мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, алардан файдалану, популярлаштыру» ярдәмче программасы Арча муниципаль районы музей фондын саклауга, өйрәнүгә һәм популярлаштыруга, музейларны комплекслы үстерүгә, җәмгыять үсешенең иң мөһим ресурсы буларак, алар тарафыннан социомәдәни функцияләр башкару өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында, шулай ук Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларын саклауны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итүгә юнәлтелгән.

«2021-2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасы гражданнарга аларның мәгълүматтан һәм белемнәрдән иркле файдалануга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерүгә, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклауга юнәлтелгән.

«2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру» ярдәмче программасы халыкның милли һәм музыка традицияләрен саклап калу һәм үстерү, үзешчән сәнгать һәм халык иҗатын үстерү, мәдәни-ял итү чаралары уздыруның сыйфатын арттыру максатын куя. Районның муниципаль мәдәни-ял итү учреждениеләре челтәренең бүгенге торышы, 2025 елга кадәр мәдәни-ял итү учреждениеләрен үстерү перспективалары чагылыш таба.

«2021-2025 елларга төбәкара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү» ярдәмче программасы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының мәдәни-тарихи һәм мәдәни-инновация үзәге буларак дәрәҗәсен күтәрүгә, Арча муниципаль районында яшәүче халыкларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклауга юнәлтелгән мәдәни акцияләр һәм чаралар системасын булдыруга, район халкы арасында түземлелек (толерантлык) тәрбияләүгә юнәлтелгән.

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2021 - 2025 еллар.

## Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү законнарда билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет, республика бюджеты, шулай ук Арча муниципаль районы бюджеты акчаларыннан файдалануны күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 571311,25 мең сум тәшкил итә. Программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фаразлау характерында һәм бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында муниципаль заказчы-координатор төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны гамәлгә ашыруның барышын һәм акчаларны турыдан-туры башкаручыларның нәтиҗәле файдалануын тикшереп тора. Программа чараларын гамәлгә ашыру программа чараларын башкаручыларның барысы белән дә программада төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе:

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр, Арча муниципаль районының икътисад бүлегенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүматны, шулай ук финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеген тапшыра;

ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр, Арча муниципаль районының икътисад бүлегенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру эшләренең барышы һәм аны гамәлгә ашыру өчен акчалардан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат бирә.

## Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Мәдәниятнең хәлиткеч үзенчәлеге шунда ки, мәдәни эшчәнлекнең иң мөһим нәтиҗәләре тиз вакыт эчендә күренми һәм акыл үсешендә, аерым кешеләрнең кыйммәт ориентирлары һәм үз-үзен тоту нормалары үзгәртүдә чагыла, бу ахыр чиктә җәмгыять яшәешенең нигезе үзгәрүгә китерә.

Программада мәдәни эшчәнлекнең агымдагы нәтиҗәләрен генә характерлаучы индикаторлар һәм цифрлы күрсәткечләр системасын куллану күздә тотыла. Шул ук вакытта тәгаен ярдәмче программаларның үз нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булырга мөмкин. Программаны һәм ярдәмче программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү Программаның координаторы - муниципаль заказчы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашырудан төп социаль-икътисадый файда Арча муниципаль районы гражданнары тормышында мәдәниятнең социаль ролен арттыруда һәм, димәк, Арча муниципаль районында яшәеш сыйфатын яхшыртуда, мәдәният өлкәсендә модернизацияләүне гамәлгә ашыру өчен уңайлы иҗтимагый атмосфера тудыруда чагыла. Бу нәтиҗә, аерым алганда, түбәндәгеләрдә чагылачак:

Арча районында яшәүче халыкларның үзенчәлеген саклап калуга ярдәм итә торган мәдәни киңлекнең бердәмлеген ныгытуда;

иҗади эшчәнлек, халыкка тәкъдим ителә торган мәдәни байлыкларның һәм мәгълүматның мәдәни һәм сәнгати иҗадилыгы, төрлелеге һәм һәркем файдалана алырлык булуы өчен уңай шартлар тудыруда;

мәдәниятне икътисадый үстерү процессларын активлаштыруда һәм

тармакка җәлеп ителә торган дәүләтнеке булмаган ресурсларны үстерүдә;

ирекле хезмәт базары шартларында, шулай ук яшьләргә эстетик тәрбия бирүне үстерүдә яшь белгечләренең конкуренциягә сәләтлелеген тәэмин итүдә.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге максатчан индикаторларның һәм Программада каралган күрсәткечләрнең фактагы казанышлары дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

**«2021 - 2025 елларга музей эшен үстерү, мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру» ярдәмче программасы**

## Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021 - 2025 елларга музей эшен үстерү, мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру» (алга таба - Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Казан арты» тарих-этнография музее» муниципаль бюджет учреждениесе |
| Ярдәмче программаның максаты | Җәмгыять үсешенең иң мөһим ресурсы буларак, алар тарафыннан социаль-мәдәни функцияләр башкару өчен музейларны комплекслы үстерү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Арча районы музей фондын саклау, өйрәнү һәм туплау.<br>2. Арча муниципаль районы музей фондын популярлаштыру.<br>3. Музейлар тарафыннан мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.<br>4. Музейларны мәгълүматлаштыру.<br>5. Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының сакланышын һәм алардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2021 - 2025 еллар |
| Ярдәмче программаны еллап финанслау күләмнәре | Арча районы бюджеты хисабына ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 34613,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2021 ел - 6 922,8 мең сум<br>2022 ел - 6 942,7 мең сум<br>2023 ел - 6 916,0 мең сум |

| | |
|---|---|
| | 2024 ел - 6 916,0 мең сум<br>2025 ел - 6 916,0 мең сум<br>Искәрмә: ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле финанс елына Арча муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыру мөмкинлеге бирәчәк:<br>реставрацияләүне таләп итә торган предметлар санының төп фондның реставрацияләнгән предметлары өлеше,<br>дәүләт исәбенә һәм саклауга куелган музейларның төп фонды предметлары санының ел башына карата ел ахырына нисбәте 120 процентка кадәр;<br>янгыннан саклау системалары белән җиһазланган музей мәйданнары өлеше 100 процентка кадәр;<br>төп фонд предметларының гомуми санының музей әйберләрен актив күрсәтүдә җәлеп ителгән чагыштырма нисбәте 75 процентка кадәр;<br>узган елга карата хисап чорында музейларга йөрү нисбәте 100 процентка кадәр;<br>узган елга карата хисап чорында гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренең һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларның музейларга йөрү саны 70 процентка кадәр;<br>узган елга карата хисап чорында ачылган үз фондлары күргәзмәләре саны 75 процентка кадәр;<br>музей предметларының гомуми санының электрон каталогка кертелгән музей предметлары саны 30 процентка кадәр;<br>хезмәткәрләрнең гомуми санының компьютерлаштырылган эш урыннары саны 100 процентка кадәр;<br>Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының гомуми санының канәгатьләнерлек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары өлеше. |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

Арча муниципаль районы музейлар челтәре үз эченә ике филиалны һәм бер бүлеге булган 1 музей учреждениесен ала.

Арча муниципаль районы музейлары структурасы
(дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклары филиалларыннан тыш)

| Музей тибы | Саны |
|---|---|
| Тарихи-туган якны өйрәнү | 1 |
| БАРЛЫГЫ | 1 |

Арча муниципаль районы “Казан арты” тарих-этнография музее” МБУ структурасына керә:

- әдәбият һәм сәнгать бүлеге, Арча ш., 1 нче Май ур., 12 йорт.
- “Әлифба” музее, Арча шәһәре, Вагыйзовлар урамы, 14 йорт;
- М.Мәһдиев музее, Гөберчәк авылы, М.Мәһдиев ур., 72 йорт.

Музей социаль-мәдәни, фәнни-тикшеренү, экскурсия, агарту функцияләрен башкара, күчемле һәм күчемсез мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне саклый һәм куллана һәм туристлар кабул итә. Музей экспозицияләре Казан арты Арча ягы үзәге мисалында татар халкының тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен чагылдыра. Вакыйгалар, кешеләр, эшләр, казанышлар - бу фрагментлардан музей тарихы тора да инде.

“Казан арты” Арча тарих-этнография музеенда 16480 берәмлек предмет, шул исәптән төп фонд предметлары - 12784 бер., фәнни-ярдәмче фонд предметлары - 3788 берәмлек предмет саклана. Шулардан 10850 берәмлек “Казан арты” музеенда, 3276 берәмлек әдәбият һәм сәнгать бүлегендә саклана, 1438 берәмлек - “Әлифба” музеенда, 916 берәмлек - М. Мәһдиев музеенда.

Музейда 85 урынга исәпләнгән конференц-зал, фәнни бүлек, музей фондларын саклау өчен бүлмәләр бар. “Әлифба” музее базасында экскурсоводлар мәктәбе эшли.

Музейларга килүчеләрнең төп төркемнәре булып гаиләләр, балалар, яшьләр, килүчеләрнең ташламалы категорияләре (пенсионерлар, инвалидлар һ.б.) тора. Бүген музейлар тарафыннан эшләнә торган төрле программалар һәм акцияләр күпчелек дәрәҗәдә нәкъ менә шушы максатчан төркемнәргә юнәлтелгән.

Район халкының мәдәни кыйммәтләр белән танышуы күргәзмәләр оештыру юлы белән генә түгел, ә күчмә күргәзмәләр, массакүләм чаралар үткәргәндә күргәзмәләр, Татарстан Республикасы музейлары һәм Россия төбәкләре белән уртак күргәзмәләр кебек эш формалары буенча да тормышка ашырыла.

Музей эшчәнлегенең хәл ителергә тиешле проблемалары

музейларның матди-техник базасының үсеше җитәрлек булмау;

музейларны янгыннардан саклау сигнализацияләре, махсуслаштырылган экспозиция-күргәзмә һәм фонд җиһазлары белән тәэмин ителмәү;

барлык музей фондын мәдәни-мәгариф, фәнни-агарту максатларында актив файдаланмау;

муниципаль музейларны мәгълүматлаштыруның җитәрлек булмавы;

инфраструктура үсешенең йомшак булуы аркасында мәдәни туризмны үстерү җитәрлек дәрәҗәдә булмау.

SWOT-анализ

| Көчле яклар | Йомшак яклар |
|---|---|
| 1. Музей фондының сыйфат һәм сан дәрәҗәсе.<br>2. Музей белгечләренең һөнәри дәрәҗәсе югары булу.<br>3. Музей эшендә традицияләр өстенлеге.<br>4. Музей биналары төзү һәм реконструкцияләү.<br>5. Массакүләм мәгълүмат чараларында музейларның эшчәнлеген киң яктырту.<br>6. Уртак күргәзмә проектларын оештыру өчен республиканың әйдәп баручы музейларын җәлеп итү | 1. Музейларның матди-техник базасы түбән булу.<br>2. Дәүләт музейларын җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүматлаштырмау.<br>3. Медиаресурслардан, аерым алганда, социаль челтәрләрдән нәтиҗәле файдаланмау. |
| **Мөмкинлекләр** | **Каршылыклар** |
| 1. Программаны гамәлгә ашыруга дәүләт һәм иҗтимагый ярдәм.<br>2. Яңа мәгълүмат системаларын кертү | 1. Программаны финанслау тулы күләмдә түгел.<br>2. Программа белән нәтиҗәле идарә итмәү.<br>3. Административ каршылыклар.<br>4. Экспонатларны реставрацияләү булмау сәбәпле, аларның юкка чыгуыюгалту |

**Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чараларны финанслау**

| Төп чараларның атамасы | Башка ручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2021 ел (база елы) | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Музей фондын тарих һәм мәдәният һәйкәлләре белән тулыландыру | музейлар | 2021 - 2025 | Дәүләт исәбенә һәм саклауга куелган музейларның төп фонды предметлары санынының ел башына карата ел ахырына нисбәте, % | 112 | 114 | 116 | 118 | 120 |
| Музейларны янгыннардан саклау системалары белән тәэмин итү | музейлар | 2021 – 2025 | Янгын сагы системалары белән җиһазланган музейларның мәйданнары өлеше, % | 90 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Музей фондын мәдәни-мәгариф, фәнни-агарту максатларында файдалануны активлаштыру | музейлар | 2021-2025 | Музей әйберләрен төп фонд предметларының гомуми санына карата актив күрсәтүдә җәлеп ителгән чагыштырма авырлыгы, % | 5,5 | 6,0 | 6,5 | 7,0 | 7,5 |
| Реклама һәм PR- | музейлар | 2021 - 2025 | Узган елга карата хисап | 90 | 100 | 100 | 105 | 105,5 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эшчәнлекне активлаштыру | | | чорында музейларга йөрү саны, % | | | | | |
| Күргәзмә эшчәнлеген активлаштыру | музейлар | 2021 - 2025 | Узган елга карата хисап чорында ачылган күргәзмәләр саны, % | 55 | 60 | 65 | 70 | 75 |
| Социаль якланмаган гражданнар төркемнәре, шулай ук мөмкинлекләре чикләнгән затларның музейларга йөрүен оештыру | музейлар | 2021 - 2025 | Узган елга карата хисап чорында гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренең һәм хисап чорында мөмкинлекләре чикләнгән затлар тарафыннан музейларга бару саны, % | 50 | 55 | 60 | 65 | 70 |
| Музейларны компьютер техникасы белән тәэмин итү | музейлар | 2021 - 2025 | Хезмәткәрләрнең гомуми санына карата компьютерлаштырылган эш урыннары саны, % | 50 | 53 | 56 | 59 | 62 |

## II. Ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары, аны гамәлгә ашыруны сроклары һәм ахыргы нәтиҗәләре

Ярдәмче программаның максаты - алар тарафыннан социаль-мәдәни функцияләр башкару өчен һәм җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак музейларны комплекслы үстерү.

Әлеге максатны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Музей фондының дәүләт өлешен саклау, өйрәнү һәм туплау.
2. Музей фондының дәүләт өлешен популярлаштыру.

3. Музейлар тарафыннан мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

4. Музейларны мәгълүматлаштыру.

5. Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының сакланышын һәм алардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру срогы - 2021 - 2025 еллар.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме район бюджеты хисабына 34613,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2021 ел - 6 922,8 мең сум
2022 ел - 6 942,7 мең сум
2023 ел - 6 916,0 мең сум
2024 ел - 6 916,0 мең сум
2025 ел - 6 916,0 мең сум

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

## IV. Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру районның музей өлкәсендә булган барлык ресурслары белән нәтиҗәле идарә итүгә (мәдәни-тарихи, кадрлар, матди-техник) ярдәм итәчәк, бу исә музейлар күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртырга ярдәм итәчәк. Болар барысы да, гомумән алганда, республиканың мәдәни мирасын популярлаштыру юлы белән Арча районының җәлеп итүчәнлеген формалаштырачак.

«2021-2025 елларга музей эшен үстерү,
мәдәни мирас объектларын
(тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен)
саклау, файдалану, популярлаштыру»
ярдәмче программасына кушымта

## «2021-2025 елларга музей эшен үстерү, мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру» ярдәмче программасының төп чаралары

| № | Эшләрнең эчтәлеге | Үтәү сроклары | Финанслау чыганаклары | Финанслауга ихтыяҗ, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1. | Семинарларда, киңәшмәләрдә, конференцияләрдә, квалификация күтәрү курсларында, һөнәри белем бирү, чаралар (экскурсияләр, лекцияләр, очрашулар) үткәрү | 2021-2025 | Җирле бюджет | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 2. | Вакытлы басмаларга язылу | 2021-2025 | Җирле бюджет | 31,7 | 31,7 | 31,7 | 31,7 | 31,7 |
| | | | **БАРЛЫГЫ** | 41,7 | 41,7 | 41,7 | 41,7 | 41,7 |

**«2021 - 2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасы**

**Ярдәмче программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2021 - 2025 елларга китапханә эшен үстерү» (алга таба - ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе |
| Ярдәмче программаның максаты | Гражданнарга аларның мәгълүматтан һәм белемнәрдән ирекле файдалануга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек китапханәләр хезмәте күрсәтү системасын үстерү, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калу |
